ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.12.2024 п.г.т. Алексеевское № 603

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 02.04.2024 ел, № 123 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы дәүләт һәм муниципаль физкультура спорт оешмаларында спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләү бирү Тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының хезмәткәрләренә - яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.10.2019 ел, № 979 карарына үзгәрешләр кертү хакында» 07.03.2024 ел, № 127 карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы Татарстан Республикасы Алексеевск районының спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләренә айлык һәм бер мәртәбә стимуллаштыручы өстәмәләр бирүне төгәлләштерү максатларында

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче, спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләү бирү тәртибенә» түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның өченче абзацында «20 000» саннарын «100 000» саннарына алмаштырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**